*«Музей — кешелек, халык, миллəт хəтере генə түгел, ə музейга килүчелəргə педагогик йогынты ясау чарасы да».*

*(В.Старцев «Музей педагогикасы турында»)*

**Кереш өлеш.**

Туган ил - ул яшəгəн җиребез, авылыбыз, безне чолгап алган ятаткан табигать, без белгəн һəм хөрмəт иткəн кешелəр. Һəркем өчен иң изге, иң якын, иң кадерле сүзлəр ул – Туган ил, Туган җир. Кеше кайда гына булса да, һəрвакыт əти-əнисен, туган ягын искə төшерə, алар белəн бəйлəнешле хəтирəлəрен яңарта.

**Музей тарихы**.

Безнең мəктəптə "Туган якны өйрəнү" музее эшли. Музей 1995 елда оеша. Башта аның өчен зур булмаган кечкенə генə бүлмə бүленеп бирелə. Ул вакытта мəктəпнең директоры Нигматуллина Лəлə апа була. Ə 2012 елда, мəктəбебезнең элеккеге директоры Саттарова Голинə Рөстəм кызы эшлəгəн дəвердə ул якты, зур бүлмəгə күчерелə. Музейдагы экспонатлар бик озын юллар, күп куллар аша үтеп, музейда үзлəренең урыннарын алдылар.

. Еллар буена җыелган материал, экспонатлар музей фондына нигез булдылар. Еллар узган саен фондыбыз тулылана гына бара. Мəктəп музееның төп бурычы – туган якның тарихын, материалларын саклау гына түгел, ə

татар халкының гореф-гадəтлəренə,йолаларына мəдхəббəт тəрбиялəү, туган якны , туган авылны яратырга өйрəтү.

Музейның төп максаты: Музей предметлары аша укучыларны белемле, тəрбияле, əхлаклы шəхеслəр итеп үстерү.

Мəктəп музее - ул мəктəпнең дəвамы, чөнки укучылар музейда тарих, əдəбият, география һəм башка дəреслəрдə ишеткəннəре турында фикер йөртүне дəвам итəлəр. Мəктəп һəм музей укучыларда патриотизм тəрбиялəүдə бербөтен тəрбия үзəге булып тора.

.

Музейга экскурсиялəр тəҗрибə, тормыш белəн бəйлəп алып бару шəхеснең белемен, хис, тойгыларын баета. Шуңа да туган ягыбыз, авылыбыз, мəктəбебез тарихында якты эз калдырган шəхеслəр белəн һəрдаим таныштырып бару максатында планлы экскурсиялəр ясала. Бу очракта төбəк

компоненты мөһим урын алып тора. Шуңа туган як тарихына багышланган материалларны туплауга укучылар да җәлеп ителә. Эзләнүләр барышында без мәктәп программасында каралмаган күп кенә фәнни дисциплина нигезләре (генеалогия, археология, этнография, музей белеменең төп төшенчәләре) белән якыннан танышабыз.

Музеебызда 250 ләп экспонат исәпләнә, шуларның барысы да төп нөсхә. Һәр экспонат аерым инветарь дәфтәргә теркәлеп бара. Биредә

“Авыл халкының көнкүреш тарихы”,

“Халкыбызның күңел бизәкләре”,

“Пионер тарихы”,

“Мәктәп тарихы”,

“ Колхоз тарихы”,

“Сугышчан дан”

“Шәҗәрәләр ”

“Нумизматика” бүлеге

“Заһидулла Шәфигуллин тормышы “

кебек бүлекләр бүлеп куелган.Бүлекләр буенча эзләнү эшләре алып барыла, алар бәрабәренә фондыбыз тагы да тулылана, байый. Дәвамлы рәвештә яңартылып торучы экспозицияләребез дә бар. Барысы турында да бәйнә –бәйнә сойлисе , күрсәтәсе килә...Кайберләрендә тулырак тукталып китик.

**“Авыл халкының көнкүреш тарихы “ бүлеге.**

Монда халкымның көндәлек тормышта кулланган әйберләре: эш коралларыннан кул тегермәне, туку орчыклары, җеп эрләгеч, сугылган тастымаллар, хатын-кызларның һәм ирләрнең милли киемнәре, чабата, бишек һәм башка әйберләр урын алган. Авыл халкы иген игү белән беррәттән сүс эрләп киндер суккан, йон эрләп тула баскан, юкәдән чабата үрү, итек басу белән дә шогыльләнгән. Почмак якта хатын-кызлар ашарга

әзерләгән.Монда агачтан ясалган савыт-сабалар, борынгы самовар, агач кашыклар, җилпүч, агач көрәк, чабагач, киле, шулай ук тормыш-кирәк-яракларыннан төрле керосин лампалары, керосинка, , кайчы, үлчәуләр, күмер үтүге һ.б. сакланган.

Татар халкы элек-электән, тырыш,эшчән,һәм кунакчыллык сыйфатлары белән танылган. Безнең музейдагы эш кораллары һәм савыт – сабалар моңа дәлил булып торалар.Шушы чуеннарда кимендә җиде-сигез кешедән торган гаиләләр өчен тәмле азык хәзерләгәннәр,пешкән ризыкны мичтән ухват белән тартып чыгарганнар.

Зур гына ак мич тә – татар халкының чисталыгын, уңганлыгын , пөхтәлеген күрсәтә. Мичтә аерым урын ясала торган булган. Аны мич башы дип йөрткәннәр. Өйне җылыту өчен салам, тирес сугып якканнар. . Бала бишеген дә мич янына җылыга элгәннәр.

**Халкыбызның күңел җәүһәрләре бүлеге.**

Менә алар—халкыбызның күңел җәүһәрләре, җаны хакында сөйләүче бу чигүле эскәтер-сөлгеләр, милли күлмәкләр,купшы калфаклар-түбәтәйләр, гаҗәп нәфис чулпылар-алкалар, ачык бизәкле, бөтен дөньяга билгеле - күн читекләр...

Элекке заманда күпчелек хатын-кызлар озын бәби итәкле күлмәкләр һәм ак алъяпкычлар кигәннәр.

Күлмәкне бер генә төсле тукымадан — атластан, парча, ефәк, сатиннан утыртма яка белән, изүен ачык итеп теккәннәр. Күлмәкне кайвакыт киң бөрмәләр белән бизәгәннәр. Авыр, төсле тукымалардан— бәрхет, сукно, парча, ефәктән тегелгән камзул озын яисә кыска җиңле һәм җиңсез озын жилетны хәтерләткән.

Бизәкләп туку өй һөнәрчелеге һәм вак мануфактуралар рәвешендә яшәп килгән. Татар кызлары һәм хатыннары борын-борыннан, сәгатьләр буе туку станогы артында утырып, үзләренә бирнә, туган-тумачаларына һәм кияүләренә, сабантуйга бүләкләр, йорт өчен чаршаулар, кашагалар, сөлгеләр әзерләгәннәр.

Декоратив иҗатның бүтән төрләре белән чагыштырганда, чигү киңрәк таралган булган. Авыл хатын-кызлары бала чактан ук чигәргә өйрәнгәннәр, кияүгә чыгарга бирнә һәм туй бүләкләре әзерләгәннәр.
Чигү өчен төрле тукымалар—үзләре суккан һәм сатып алган тукымалар, ефәк, парча, бәрхет, сатин кулланылган.

Элек-электән оста куллы хатын-кызларыбыз мавыктыргыч кул эшләренә бөтен тырышлыкларын куеп, зәвык белән милли киемнәр теккәннәр. Кышкы

озын төннәрдә кызлар, яшь киленнәр аулак өйләрдә кич утырып йон эрләгәннәр, оекбаш-бияләй бәйләгәннәр. Ир-атлар чабата үргәннәр,савыт-саба ясаганнар.Олы яшьтәге апалар,Коръән сурәләре укыганнар,ә әниләр үзләренең балаларына бишек җырлары җырлаганнар һәм кызыклы әкиятләр сөйләгәннәр.

.Эштән соң өстәл янына утырып менә шушындый җиз самавырдан чәй эчкәннәр.Бәйрәмнәрдә чәй янына төрле тәмле ризыклар куелган:чәк-чәк,кош теле,бавырсак кебек милли ризыкларыбыз табынның күрке булып торган.

**“Пионер тарихы, уку почмагы”** бүлегендә барабан, кызыл галстук, элеккеге укучылар формасы, кызыл байраклар урын алган. Шулай ук элеккеге парта, отряд көндәлекләре, уку әсбаплары, грамоталар саклана.

**“Мәктәп тарихы” бүлегендә** мәктәбебезнең оешу елларыннан алып бүгенгә кадәр хезмәт куйган укытучылар турында шәҗәрә агачы бар.

**“Колхоз тарихы”.** 1929 елның язында колхоз төзелү башлана. Иң беренче – 14, язгы кыр эшләрен башлаганчы 31 хуҗалык берләшә**.**Презентацияда сез колхоз тозүдә актив катнашучыларны күрәсе**з.**

Музейның бу бүлегендә колхоз чорына караган куп кенә эш кораллары, китаплар урнаштырылган. Шулай ук колхоз хезмәтчәннәренең хезмәт кенәгәләре һ.б шундый төрле документлар бар.

**Музеебызнын Боек Ватан сугышы елларына багышланган бүлеге.**

Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Ватан сугышы беткәнгә дә инде 75 ел. Әмма сугыш хатирәләре, дошманга күкрәк киереп каршы торган, изге җиребезне саклап калган, аның иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнар һичкайчан онытылмас. Ватаныбызны явыз дошманнан саклау өчен\, сугышка киткән 136 авылдашыбыз кире әйләнеп кайтмаган. Кешеләр йөрәгендә сугыш калдырган яралар һаман да сыкрый шул әле. Сугыш афәтен башыннан кичергән кешеләр кабат сугыш булуын һичкайчан теләмәсләр

Менә алар...Өчпочмаклы хатлар!!! Күпме сагыну, ярату хисе ята аларда...

Э менэ монысы Җинү коне уңаеннан бүләк ителгән чашка.

Бүгенге тыныч тормышыбыз, аяз күгебез, мул табыныбыз өчен башын салган авылдашларыбыз рухы тыныч булсын. Без аларга рәхмәтле.

Сугыш кырында җиңү яулап кайткан фронтовик авылдашларыбыз безнең арабызда юк инде. . Ләкин, бүгенге бәхетле тормыш, хөрлек һәм бәйсезлек өчен көрәшүчеләр. Алар – җиңүчеләр!

**“Шаҗәрәләр” бүлеге** аеруча күңелгә якын. Мәктәбебезнең һәр укучысы агач формасы рәвешендә узләренең гаиләсенең буыннар чылбырын төзеде. Кулымда минем өчен бик тә кадерле булган гаиләмнең шәҗәрәсе. Әби бабайлар яшәгән гомер - ул безнең милләтебезнең дә узган юлы, тарихы. Менә шуңа күрә дә үз нәселеңнең тамырларын белергә, белмәсәң эзләп табарга кирәк дип уйлыйм мин. Монда минем 9 буын тарихы. Шәҗәрәгә карыйм да, бабамнарның исемнәрен укыйм, аларның төс –кыяфәтләре, холыклары нинди булды икән дип уйлыйм. Гомер уза, яңадан яңа буыннар туа тора. Бездән соң килүче буыннар да безне барлап, искә алсыннар дисәк, ерак бабаларыбызны онытмыйк, һәрчак истә тотыйк, алар белән горурланыйк!

Нумизматика бүлеге

Биредә Акъегет авылында һәм якын тирәдә табылган металл акчалар һәм соңгы еллардагы кәгазь акчалар күрсәтелә.

Нумизматика бүлегендә рус һәм чит ил акчалары. Алар рус дәүләтенең үсеш этапларын ачык чагылдыралар. Мәгълүматлардан күренгәнчә, “деньги” сүзе борынгы төрки сүзеннән дип уйлана. Музейга акчаны укучылар бик күп бүләк иттеләр. Алар арасында иң элеккесе – 1797 елгы акча. VIII, XIX гасыр акчалары белән, Советлар Союзы елларныкы да бар.

“Заһидулла Шафигуллин тормышы “ бүлеге.

Заһидулла Шәрифуллин – икенче гильдияле купец, меценат, Казан губернасы Чуел өязе Акъегет авылында туа. 1861 елда себергә китә. Агач хәзерләүдә тырышып эшли. Берничә елдан алтын юуучы булып китә.Алтынга бай урынны таба. Иркутскида кибет ачып җибәрә.,мехлар сата.

1876 елда Акъегеткә әйләнеп кайта. Йорт сала. Мәктәп салдыра. Икенче кайтуында манаралы мәчет бурата.

20 гасыр башында инде туган авылына даими яшәү өчен кайта.

Туган авылында Заһидулла хаҗи 1872 нче елда Чуел өязендә бердәнбер ирләр мәдрәсәсе салдыра, икенчесен ремонтлата, үз акчасына 3 мәчет, 2 катлы ирләр, бер катлы кызлар мәктәбе ачтыра. Аларда 350 бала укый. Авыл уртасындагы сазлыклы урынга агачлар утырттыра. Имами кизләвеннән таш юл салдыра, Шушы хезмәтләре өчен авыл халкы аны хөрмәтләп искә ала. Шафигуллин картлык көнендә сукырая. Октябрь революциясеннән соң авылдан китәргә теләми. 1919 елда үлә һәм авыл зиратына күмелә.

Йомгаклау. “Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк”, диләр. Туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, туган авылның, туган мәктәпнең тарихын өйрәнү зур әһәмияткә ия.

Туган як" музеенда һәрбер әйбер бай һәм тарихи әһәмияткә ия. Чөнки һәр экспонатта ата-бабаларыбызның күңел җылысы, аларның рухы, изге хатирәләре саклана.